**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 40-9 25 июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2017 елның 29 сентябрендәне 63-18 нче номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелешен проектлау нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрен проектлау нормативларына үзгәрешләр кертү турында (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38, 12.03.2020 №164-41 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын үтәү йөзеннән, 2021 елның 05 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 27 июлендәге 1122 нче номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2019 елның 19 сентябрендәге 557/пр номерлы боерыгы нигезендә, ,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәр Советы карар **итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советының 2017 елның 29 сентябрендәне 63-18 нче номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәренең шәһәр төзелешен проектлау нормативлары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәрен проектлау нормативларына (13.12.2018 №120-29, 23.05.2019 №137-33, 20.08.2019 №144-35, 22.10.2019 №151-36, 12.12.2019 №156-38, 12.03.2020 №164-41 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 бүлекнең 4.2.37 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Каралты төзелеше районнарында ераклыкны түбәндәгечә кабул итәргә кирәк (42.13330.2016):

Күрше җир кишәрлекләрендә урнашкан торак бина (бүлмәләр, кухня һәм веранд) тәрәзәләреннән йорт диварлары һәм хуҗалык корылмаларына (сарай, гараж, мунча) кадәр аралар 6 метрдан да ким булмаска тиеш. Участок чикләреннән ераклык түбәндәгедән ким булмаска тиеш, метрларда: торак йорт диварына кадәр - 3; хуҗалык корылмаларына кадәр-1. Үзәкләштерелгән канализация булмаганда,

бәдрәфтән якындагы йорт диварларына кадәр араны 12 метрдан да ким булмаган, су белән тәэмин итү чыганагына кадәр (кое) - 25 метрдан да ким булмаган араны кабул итәргә кирәк".

1.2. 4.8 бүлектә:

а) 4.8.18 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үләт базлары (биотермик чокырлар) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2020 елның 26 октябрендәге 626 нчы номерлы боерыгы белән расланган, биологик калдыкларны йөртү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерүнең Ветеринария кагыйдәләре таләпләре нигезендә проектлана.»;

б) 4.8.21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Санитар-саклау зонасы күләме тәшкил итә:

- чокырларда күмелгән үләт базыннан-1000 м;
- биологик камералы үләт базыннан-500 м.».

1.3. 6.1 бүлектәге 6.1.7 пунктта «шәхси гараж» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен гаражлар төзү» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 1 нче кушымтаның "Ветеринария-санитария кагыйдәләре» бүлегендә :

а) «Ветеринария-санитария кагыйдәләре» сүзләрен «Ветеринария кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2020 елның 26 октябрендәге 626 нчы номерлы Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы белән расланган,«Биологик калдыкларны күчерү, саклау, эшкәртү һәм утильләштерүнең ветеринария кагыйдәләре».

2. Әлеге карарның 1.3 пункты 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай муниципаль районы Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин